


Темников районы «Аксел» хужалыгы-нын кызган чагы: уныш очен корәш дәвам итә. Игенчеләр очен ин кызу һәм бик жаваплы чор – ул урып-жыю. «Аксел» (Аксель авыл жирлеге) очен бу ел кvк канцеляриясе бунты аркасында нык-лыкка чын сынау булды. Кон саен ялыктыргыч янгыр яуды, алтын вакытны чиксез котvгә әйләндерде.
- Моннан сигез-тугыз ел элек шундый жәй булды, ул вакытта да туйганчы янгыр яуды, - дип искә ала хужалык механигы Ряшит Дулатов. - Һава торышы яхшы булганда техника тигез барды, ашлык коры, югалтулар минималь иде.       Дымлы ашлыкны киптерv комплекслары аша икешәр тапкыр vткәреп киптердек. Бу икеләтә эш предприятие икътисадына авыр йок булып ятты.
Һава торышы саботажына карамас-тан, әлеге катлаулы сезонда уныш гектарыннан 30 центнердан артык тәш-кил итә. Козге рапс, арыш, арпа, бодай һәм борчак тулысынча жыеп алынган инде. Кырда сабан культуралары - соя, житен калган. Штурвал артында утыручыларнын алтын кулларыннан башка теләсә нинди технологияләр кочсез. Авыл хужалыгы жирне яратучы һәм техниканы бик яхшы белvче кешеләр жилкәсендә тора. Ветераннар янында яшь смена чыныга. Шамиль Мамлеев – КамАЗ машинасы йортvчесе. Хужалыкта оченче ел эшли. Егерме ел хужалыкта булмаганнан сон (Санкт-Петербургта эшләгән) ул vзенен туган Тарханына кайтырга карар кыла. Шамиль унышлы шофер да, автослесарь да. Техника белән ул 12 яшьтән бирле дус һәм кыенлыклардан курыкмый. Яз башын ул кырга орлык белән ашламалар ташый, жәен чәчvлекләрне эшкәртv очен су китерә; кыр белән ферма арасында печән, салам һәм тирес белән йори. Тагы авыл хужалыгында булган бик кvп эшне башкара ул. Нәкъ менә шундый кешеләр житештерv циклынын озлексезлеген тә- эмин итә. Бу кешеләр тан атканчы торалар, эссе кояш яки коеп яуган янгыр астында эшлиләр, урак вакытында атналар буе ял коннәрен кvрмиләр. Алар унышны vстереп кенә калмыйлар. Алар илнен азык-толек иминлеген тәэмин итеп, алдан фаразланмаган һава торышына, глобаль икътисадый кризисларга каршы тора. Шундый ирләр жирдә топ эшне эшлиләр, кешеләргә икмәк әзер-лиләр.

**Наилә НАСЫРОВА әзерләде,**

**Фото: “Темниковские известия”дән**